Республика Татарстан
Сармановский
муниципальный район
Исполнительный комитет
Азалаковского сельского поселения
423371 с. Азалаково ул Зеленая дом 8В
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Башкарма комитеты

423371 Азалак авылы Яшеллек урамы
8В йорты.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.01.2022 ел №1

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Азалак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6964,68 сум күләмендә курсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 29 январендагы 1 номерлы карарын уз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO. TATARSTAN.RU) Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Азалак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: И.Г.Габдулгазизов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4011,67 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1504,36 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2022 елның 28 гыйнварындагы
1 номерлы карарына 2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1337,91 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2668,19 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1509,93 |
| Барлыгы | 6964,68 |